
**Бәләбәй районының “Үзәк биләмәара китапханәсе” муниципаль автоном мәдәният учреждениесе.**

**Милли әдәбият һәм туган якны өйрәнү бүлеге.
Үзәк китапханә.**



# ТУКАЙГА ШИГЬРИ ЧӘЧӘКЛӘР

## Бәләбәй шагыйрьләренең Габдулла Тукайга арналган шигырьләре

**Бәләбәй, 2023**

84 (2Рос=Баш)
Т 72

Төзүче: Сәлимова Р.М.

## Укучыга сүз!

Телсез идек – Тукай безне телле итте.
Җырсыз идек – Тукай безне җырлы итте.
Сәйфи Кудаш

Шагыйрь Тукай, шәхес Тукай, тарих Тукай... Һәр кем аны үзенчә яңарта, аның белән үзенчә сөйләшә. Җандашлары, Казанда һәйкәләренә чәчәкләр саладыр, шигыйрьләрен укыйдыр. Ә без шушы әдәби җыентыкта укучыларыбызга Бәләбәй шагырьләренең Тукай рухын сыендырган милли гамьле, милли чәмле шигырьләр гөлләмәсен тәкдим итәбез.

Тукай шәхесе һәм иҗаты... Бәләбәй шагыйрьләренең әсәрләрендә менә шушы үлемсезлеккә мөрәҗәгать иткән шигырьләрен беренче мәртәбә бергә туплау тәҗрибәсе бу.

Тиңсез шигъри таланты, чагу индивидуальлеге, шигъриятенең оригинальлеге татар гына түгел, ә бәлки дөнья әдәбияты тарихында Габдулла Тукайга аерым урын билгеләде. Әгәр моңа фаҗигале язмышын да кушсаң, Габдулла Тукай шәхесенең ни өчен шагыйрьләр, замандашлары һәм аннан соңгы буыннар игътибарын җәлеп итүе аңлашылып тора.

Укучым, битләрне тиз генә актарып чыгарга ашыкма. Сине билгеле һәм билгесез каләм ияләренең иҗаты белән танышу, Габдулла Тукай турында йөрәккә якын, җылы һәм ихлас сүз сайлау көтә. Бәлки, арагыздан кем дә булса: “Мин Сезне яраттым, Тукай...” – дияр.

Г. Тукай иҗатына багышлап әзерләнгән шигырьләр җыентыгы – бөек шагыйрь истәлегенә олы хөрмәт.

## “Минем һәр минутым бөтен дөнья бәһасенә тора...”

Һәр үткән көн,

Һәр мәдәни атлаган адым

Тукайны зур итәчәк,

үстерәчәк кенә...

Гаяз Исхакый

Матур яз көнендә, җылы яктан кышлар кайтканда, умырзая чәчәкләре баш калкытканда 1886 елның 26 апрелендә элек Казан артындагы авылларның берсендә мулла гаиләсендә бер ир бала туа. Атасы аңа Габдуллаҗан дип исем куша. Бу бала, дүрт яшен дә тутырмый әти-әнисез кала. Шагыйрьнең газаплы, авыр тормышы башлана.

Оядан ояга күчеп җылылык эзләп йөргән бу сабыйга Кырлай мәрхәмәтлерәк булып чыга. Бәләкәй Габдулла монда башка урыннарга караганда озаграк яши, хәттә сабакка йөри башлый. Кырлай авылында ул үзенең киләчәк иҗаты өчен нигез булачак бик куп рухи байлык туплый.

Ерак җирләрдә гомер уздырып, яңадан Казан артына кайткач, шагыйрь туган ягы турында болай яза:

Җөмләтән изге икән ич: инешең, чишмәң, кырың,

Юлларың, авыл, әвен, кибәннәрең дә ындырың;

Һәр фосулыәрбәгьән:язын, көзең, җәй, кыш көнең,

Барча, барча ак оек, киндер, чабата, ыштырың!

Һәм көтүчең, этләрең, үгез, сыер, сарыкларың;

Барчасы яхшы: бүре, җен, шүрәле, сарикъларың.

Тукайны көннәрдән бер көнне Уральскига алып китәләр. Кайгы-хәсрәте, ятимлегендә изгән, сихри табигатендә рухи яктан баеткан бишеге белән саубулашып, Габдулла әнә шундый билгесез сәфәргә чыгып китә. Алда ниләр көтә инде бу ятимне?

Уральск – шагыйрьнең журналист һәм шагыйрь буларак канат ныгыткан урыны. Журналистик эшчәнлеге Камил Мотыйгый белән башлана. Мотыгый “Фикер” газетасын һәм “Әлгасрелҗәдид”, “Уклар” журналын чыгара. Типографиядә кунеп-төнеп эшли, шигырь, мәкалә яза, тәрҗимә итә. Уральск шагыйре Габдулла Тукайны инде Казанда, Оренбургта, Петербургта яхшы беләләр.

Туган туфрак шагыйрьне Казанга тарта. Казан шәһәре аңа белем учагы, мәдәният учагы  булып күренә һәм Уральскида язган “Пар ат” шигырендә аның инде рухы белән Казанда яши башлаганлыгы күренә.

1907 елның көзеннән Тукайның Казан чоры – халкына, Ватанына шигъри сүзен әйтер өчен бирелгән биш ел да сигез айлык дәвере башлана. Тукай Казанга килүгә “Әл-ислах” газетасында, “Яшен” журналында актив катнаша башлый. Китап нәширләре алдан ук аның әсәрләрен басарга вәгьдә биреп торалар.

Шул чорда Тукай белән Фәтих Әмирхан арасында кыска, ләкин мәңгелек дуслык урнаша. Тукайның дөньяга карашларын алга таба үстереүдә иң зур рольне, әлбәттә, акыллы, тәҗрибәле Ф. Әмирхан уйнаган.

Халкының бөтен кайгы-хәсрәтен уз күңеле аркылы уздырган шагыйрь бәхетле, тыныч кына тормыш белән яши алмый. Бигрәк тә 1909-1910 еллар Тукай өчен авыр һәм газаплы булалар. Моның сәбәпләре күп була: илдәге иҗтимагый хәлләр, шәхси моментлар, көчәя башлаган өметсез авыру... Әлбәттә, болар барысы да шагыйрьнең иҗатына тәэсир итми калмаганнар.

Гомер айларының инде санаулы гына калганын Тукай аңлый. Шуңа күрә бер генә көнен дә әрәм итми, халыкка әйтәсе сүзләрен әйтеп бетерергә ашыга.

15(2) апрельдә Тукайның гомере өзелә.

Тукай безнең белән!

Бездән соң да

Барачак ул алдан юл ярып.

**Габдулла Тукай**

## ТУГАН ТЕЛ

И туган тел, и матур тел,
әткәм-әнкәмнең теле!
Дөньяда күп нәрсә белдем
син туган тел аркылы.

Иң элек бу тел белән
әнкәм бишектә көйләгән,
Аннары төннәр буе
әбкәм хикәят сөйләгән.

И туган тел! Һәрвакытта
ярдәмең берлән синең,
Кечкенәдән аңлашылган
шатлыгым, кайгым минем.

И туган тел! Синдә булган
иң элек кыйлган догам:
Ярлыкагыл, дип, үзем һәм
әткәм-әнкәмне, Ходам!

**Зәйфә Салихова**

*Башкалабыз Уфада сөекле шагыйребез*

*Габдулла Тукайга һәйкәл ачылу уңае белән*

## ТУКАЙ КАЙТТЫ

Ишет, дөнья,
ишет, җирем, күгем:
Тукай кайтты безгә
һәйкәл булып!
Ышан гына, хыял чынга аша –
Уйлыйм шушы хакта
күңел тулып.

Күпме татар
шушы хыял белән
Китеп барды, хыял сүнмәде.
Без бәхетле, алар, ни эшлисең,
Бу тарихи көнне күрмәде.

Күпме татар шушы хыял белән
Яшәде дә йомды күзләрен.
Тукай кайтты безгә!
Дога булып
Барып җитсен
шушы сүзләрем.

Йөрәгендә күптән һәрбер татар
Һәйкәл койды олы шагыйрьгә.
Тукай һәйкәле ул – чиксез сөю
Туган телгә, моңга, шигырьгә.

Тукай һәйкәле ул –
милли рухның
Яңаруы куңел түрендә.
Горурлыкка үрелеп
һич сүрелмәс
Шатлык балкый күңел күгендә.

Таш һәйкәлгә карыйм һәм...
Тукайның,
Билләһи дим, үзен күрәм күк.
Җанланыр да
үз тавышы белән
“Туган тел” диеп сөйләр күк.

Газиз халкым,
кыйблаң югалтмаска
Тукай карап тора
һәйкәл булып.
Ышан гына, хыял чынга аша –
Елыйм, көләм, җырлыйм,
күңел тулып.

***

Апрель ае, Тукай ае –
Тукай язмышы кебек:
Җылы лəйсән урынына
Салкын кар ява килеп.

Язның беренче чәчәге
Калтырап беткән өшеп.

Йолкынгандай күз алдымда
Тукай җаны, күшегеп.

Халкым йөрәген җылыткан
Шагыйрьнең үзе кебек.
Җылытасым килә өреп –
Яшәсен чәчәк көлеп.

**ТУКАЙГА ТУГАН КӨНЕНДӘ**

Тукай –намусым аклыгы,
Халкымның җан ярасы.
Арада еллар упкыны...
Ничек синңа барасы?
Каберең дә, һәйкәлең дә,
Ни кылыйм, ерак, ерак.
Саласым килгән иде бик
Кыр чәчәкләре тыйнак.
Син кабызган шигырь утын
Шигъри чәчәкләр итәм.
Башым иеп, сөеклебез,
Рухыңа синеңилтәм.

**Ә ТУКАЙ ЯШӘР!**

Безгә кадәр дә бу җирдә
Яшәлгән күпме гомер…
Чордан чорга комнар күчкән,
Җил искән күпме гомер!

Без дә килгәчтен бу Җиргә,
Яшәрбез дә  китәрбез.

Нур һәм моң чәчеп узсак та,

Онытылып бетәрбез.

Ә Тукай дигән Иманны

Киләчәк үзе дәшәр.

Иманга вакыт та баш ия –

Тукай ул яши, яшәр.

Тукай ул яши, яшәр!

**ТУКАЙ ДИСӘМ…**

Тукай дисәм,

Җанга моң тарала.

Нинди тылсымы бар бу сүзнең?

Сурәтенә карап бу хакта мин

Уйланамын, калсам берүзем.

Тукай һәм моң...

Бер үк төсле сүзләр.

Җандашлардыр, шулай тоела.

Тукай дисәм – җанга моң тарала,

Ә моң дисәм – Тукай уела.

**РӘХМӘТ, ТУКАЙ**

*Туган тел шигыренең 100 еллыгына карата*

И “Туган тел”...

Әнкәм сөте белән

Бишектән үк сеңдең каныма;

Кайда барсам, нинди гамәл кылсам,

Изге дога булдың җаныма.

И “Туган тел”,

Синдә Тукай моңы,

Мәхәббәте туган телемә;

Сине көйләп үскән һәр баланың

Күчә бара йөрәк түренә.

И “Туган тел”,

Туган җирдән читтә

Яшәгәннәр Сине җырлыйлар;

100 ел буе Сине һәр тарафта

Гимн итеп басып тыңлыйлар.

И “Туган тел”,

Синең мәкамеңнән

Сөю туды газиз халкыма,

Алыштырмам Сине, Туган телем,

Кадерлесең көмеш-алтыннан.

И “Туган тел”,

миллион йөрәкләргә

Какшамас көч булып каелдың.

Рәхмәт, Тукай, халкым яшәр өчен

Мәңгелек җыр язып калдырдың.

Мәңгелек җыр язып калдырдың.

**ТУКАЙ ДИГӘН БЕР ДӨНЬЯ БАР**

Тукай дигән гаҗәеп тә бер дөнья бар,

Тукылган ул саф намустай якты моңнан;

Илаһият, иҗтиһаттан, мәхәббәттән,

Балкый булыр шагыйранә якты нурдан

Ул дөньяны ни эзләп тә табып булмый
Җир шары, күк, планеталар картасыннан;
Әмма халкым шатланса вә хәсрәтләнсә,
Сыена гел шушы хәят яктысына.

Карта нәрсә, илләр әнә югалалар,
Кала охшап урыннары өрәкләргә.
Тукай дигән гаҗәеп тә олы дөнья
Мәңге яши, яшәячәк йөрәкләрдә.

**АПРЕЛЬ**

Салкын җиргә җылы тынын
Апрель өргән чакта
Габдуллаҗан – Апуш туган
Арча дигән якта.

Асрамага бала булып
Йөргән кулдан-кулга;
Әй ятимлек газаплары...
Кемне салмас уйга.

Бер көнөн дә ак диялми
Үскән, күпне күргән.
Гаделсезлек ни икәнен
Кечкенәдән белгән.

Йөрәк әрнүләре яшьли
Аны гамьле иткән;
Әтрәк-әләм кан калтырар
Шагыйрь булып җиткән.

Апрель улы. Гомеркәе
Гүя умырзая:
Нәфис...
Батыр...
Буламы соң
Мондай гомер зая!

Ул бит – Тукай!
Шигырь уты
Гүя тере суы;
Сүнмим дисәң, газиз халкым,
Син Тукайны укы!

Кергә батып бетмим дисәң,
Син Тукайны укы!!
Туган телең белим дисәң,
Син Тукайны укы!!!

Бәхет бит ул:
аны һәр көн,
Һәр төн укый алу.
Миннән соң оныклар укыр,
Шуны теләп калу.

Аны йөрәк күзе белән
Уку – яхшыру ул;
Зиһенең һәм яшәү рәүшең,
Дөньяң яктыру ул.

Аны йөрәк күзе белән

Уку – рухың ныгу;
Кара болыт яб(ы)рылса да
Якты булып калу.

Бишектән үк учлап-учлап
Шагыйрь моңын эчтем.
Үкенү юк – халкым өчен
Пошаманга төштем.

Күңелемдә шигырь уты,
Сиңә илтәм, халкым.
Синең өчен, кирәк икән,
Булам алкын, ялкын.

Тукай моңын эчеп үскән
Гамьсез була алмый;
Дөнья агарту юлында
Юк, ул туктап калмый.

Мөхәммәтләр, Илгизәрләр
Тукай токымыннан;
Күпме яшь йөрәк кабынды
Алар ялкыныннан.

Татар иле – Тукай иле,
Тирән тамырлары:
Йолка алмый, ник котырмый
Ажгыр давыллары.

Татар иле – Тукайлы ил,
Яши, мәңге яшәр!
Тукай әле киләчәккә
Буыннарны дәшәр.

...Салкын җиргә җылы төнен
Апрель өргән чакта
Шушы хисләр күңелемдә,
Шушы уйлар башта.

Апрель биргән генә.
Апрель алган...
Тик җәсаден генә;
Апрель яши, безнең кебек,
Тукай белән генә.
Без яшибез апрель кебек
Тукай белән генә.
Тукай белән

*Мөхәммәт – Бәләбәй татар гимназиясенең элекке җитәкчесе Нурмөхәммәт Хөсәенов.*

*Илгизәр – тел белгече, БАССР мәктәпләренең атказанган укытучысы Илгизәр Гыйззәтуллин.*

## РӘХМӘТ, ЯЗЫМ

Тамчыларың өчен, тып-тып тамган,
Сөеп, иркәләгән язларың;
Гөрләвегең өчен, борын төрткән
Нәни генә яшел үләнең;

Боз катламын тишеп калкып чыккан
Умырзаяң өчен, уҗымың;
Туган якка кайткан сыерчыгың,
Яңа көе өчен  җырымның;

Сагышларым өреп җылытуың,
Көчәйтүең өчен сагнуым;
Рәхмәт сиңа, язым, барсы өчен –
Яшәргә көч синнән алуым.

Ә шулай да рәхмәтемнең сиңа
Халкым исеменнән зурысы:
Син Тукайны бирдең – мәңге сүнмәс
Рушан йолдызының нурлысын.

Без – Тукайлы халык, гамьле, чәмле.
Тукай моңы җанда бишектән.
Давылларга каршы барган чакта
Адашмам мин, аумам, күшекмәм.

Бездә  язлар көләч кенә түгел?
Бездә язлар бөек Тукайлы.
Тукай урамыннан китеп барам,
“Туган телен” көйләп Тукайның.

**БУ КӨН**

Һәр ел шулай: бу көн туа
Кояшлы, нурлы булып;
Гомер буе озата бара
Сагышлы, моңлы булып.

Милли гамь  яңарыш ала
Милләтем йөрәгендә.
Милли кошлар өзелеп сайрый
Йөрәге тирәгендә.

Бу көн саклый без – татарны
Гамьсез мәрткә китүдән;
Кисәтә тырым-тырагай
Бүлгәләнеп бетүдән.

Бу көн өнди арынырга
Бер-беребезне ашаудан;
Дәүләтне юк  иткән хыянәт
Әнә шуннан башланган.

Бу көн үтенә, чакыра
Бердәм, бергә  булырга;
Туган телне,  туган моңны
Юл бирмәскә буырга.

Яңа көч белән яңгырый
Ана телем бу көндә.
“Туган  тел” җырын җырлаудан
Читтә калмый беркем дә.

Бу көн яшәде һәм яши
Мәңге онтылмас булып.
Үткәндә һәм киләчәктә
Мәңге җуелмас булып.

Бу язгы көн, бу матур көн
Көтеп алган көн бит ул.
Халкым бәхетенә җиргә
Тукай туган көн бит ул!

**ТУКАЙ КИТМИ!**

Тукай китkәнгә күптән дип
Әйтсәләр сезгә әгәр,
Ышанмагыз, күпләр китә,
Тик Тукай китми мәгәр.
Тукай яши язлар булып
Вакытның агышында.
Ул халкымның горурлыгы
Һәм якты сагышы да.
Моңы, җыры, рухы яши
Һәркемнең күңелендә.
Җәсад киту – табигый хәл,
Үлемсез гомере дә.
Кайтмаска киткәннәр була,
Аларның беткәне юк.
Ә Тукай...
Яшәде, яши!
Тукайның киткәне юк!
Тукайның киткәне юк!

**КЕМ УЛ ТУКАЙ?**

-Тукай абый...
Ә кем соң ул?..
Әйтеп бирче, әнкәем.
- “И туган тел” җырын язган

Зур кеше ул, бәбкәем.

Тукай дәресе...

Мөгаллим

“Шүрәле”не и сөйли.

Йотлыгып тыңлыйм.

“Пар ат”ны

И укый, көйли-көйли.

Үскән саен тар дөньяның

Читлеген ачкан бала.

Халкымның мәңгегә балкыр

Йолдызы булып кала.

Тукай кемлегенә бүген

Җавап эзләми җаным

Мине мин итеп яшәткән

Ул моңым һәм вөжданым.

## ТУКАЙ БЕЛӘН СӨЙЛӘШҮ

*...Керләнә өст-өстенә рух,*

*һич хозур вөҗданга юк:*

*Ни сәбәптән җир йөзендә*

*тәнгә – мунча, җанга – юк?!*

*Г.Тукай.*

Син яшәгән заманда да, Тукай,

Тәнгә мунча булган, җанга – юк:

Җан сатканнар вак «тиеннәргә» карап,

Керләнгән өст-өстенә рух.

Күрер идең, әгәр терелеп кайтсаң,

Минем заманда да шул ук хәл:

Тәнгә мунчаларның затлылары,
Җаннар каралуы – кемгә җәл?!

Рух керләнә катлам-катлам булып,
Шаккатарлык тышкы зиннәтләр,
Чалгы кырккан яшел үлән кебек,
Юк итеlә асыл кыйммәтләр.

Тыпырчына җаным – дөнья пычрак,
Ярый әле, Тукай, күрмисең.
Әллә күрмәс өчен бозыклыкны
Аласыңмы үзең мине соң?.
Юк, чакырма.
        Мин әлегә җирдә
Агартырга калам җаннарны.
Үз җаныма мунча эзләү өчен
Актарамын синең җырларны.

Тукай безнең белән
Безнең буын җиргә килгәнче үк
Халык- Тукай булган гел бергә.
Әсәрләрен кулдан кулга йөрткән,
Ә рәсемен элгән иң түргә.

"Су анасын", "Шүрәле"сен тыңлап,
Яшь балалар зиһен-аң алган.
Шигырьләрен укып, туган телнең
Шигъри, ак моңына таң калган.

Тиңсез шигърияте күзен ачса,
Рухландырса сөйгән милләтен,
Сагыш тулы моңсу җырулары
Тетрәндергән газиз өммәтен.

Без дә шулай.
Җиргә килгәннән үк
Тукай белән бергә атлыйбыз.
Тукай рухы белән без көчлебез,
Татарлыкны, телне саклыйбыз.

Аның “Туган тел” е безнең өчен
Икмәк кебек изге, кадерле.
Һәр тарафта яңгырый, ишетелә
Киләчәкнең үзенә кадәрле.

Тукай безнең белән!
Бездән соң да
Барачак ул алдан юл ярып.
Татар күге аяз! Тукай – якты йолдыз
Баш очында тора гел балкып.

## МИН ТУКАЙГА КИЛӘМ

Мин Тукайга сабый чактан киләм.
Әкиятләрен укып таң калам.
Шигъри гөлләренә сокланам һәм
Яшәр өчен зиһен, аң алам.

“Сөй халыкны...” васыяте җанда,
Китаплары бик еш кулымда.

Аның йөрәк сүзе гүя кыйбла,
Гүя компас гомер юлымда.

Аяк асларыннан җир киткәндә,
Тоеп фаҗигасен телемнең,
Мин Тукайга киләм, елый-елый,
Моңым эчәм, “Туган тел”енең.

Әрнегәндә уйлап кичәгесен,
Бүгенгесен газиз халкымның,
Фикерләре мәйданында йөрим
Тоеп көчен гали рухының.

Татар җаным минем гел Тукайны
Юксынып вә тора сагынып.
Килгән саен милли горурлыгы,
Кыюлыгы кала ягылып.

Киңәшергә  киләм, җылынырга,
Моңланырга, дәрман алырга.
Мыскыл ишеткәндә вак дияргә,
Киң күңелле булып калырга.

Дөнья киң булса да, читлегенә
Килеп бәрелгәндә бәгырем,
Мин Тукайны уйлап торып басам,
Мәңге яшәр халкым шагыйрен.

Гаделсезлек күрәләтә көлсә,
Йөрәк бара Тукай янына.

Көзләрдә дә, салкын кышларда да
Киләләм мин Тукай язына.

Мин генәме? Өлкән буын килә,
Яшь буыннар Тукай катына.
Шатлыклары, сагышлары белән –
Төрки дөнья Тукай янында!

Бу дөньяга килми белми калсам,
Мәңге яшәр Тукай барлыгын...
... Ә мин килдем! Һәм Тукайга киләм!
Ул иманым, вөждан аклыгым.

**ТУКАЙ БЕЗНЕҢ БЕЛӘН**

Безнең буын җиргә килгәнче үк
Халкым булган Тукай белән бергә.
Әсәрләрен кулдан кулга йөрткән,
Ә рәсемен элеп куйган түргә.

"Су анасын", "Шүрәле"сен" тыңлап,
Яшь балалар зиһен, акыл алган.
Шигырьләрен укып, туган телнең
Нечкә моңын күңеленә салган.

Кыю шигърияте күзен ачса,
Рухландырса сөйгән милләтен,
Сагыш тулы моңсу җырулары
Тетрәндергән газиз өммәтен.

Без дә шулай Җиргә килгәннән үк
Тукай белән бергә атлыйбыз.
Ул булганга, шөкер, без бәхәтле,
Татарлыкны, телне саклыйбыз.

Аның “Туган тел”е безнең өчен
Икмәк кебек изге, кадерле.
Һәр тарафта яңгырый, ишетелә
Киләчәкнең үзенә кадерле.

Тукай безнең белән! Бездән соң да
Барачак ул алдан юл ярып.
... Буген тагын оныкларым белән
Кич утырдык китабын алып.

**“ТУКАЙ. ЗАМАН. БЕЗ”** циклыннан **Кайта күрмә!**

*Нигә кайтканыңа үкенерсең,*
*Чакыралар дип, берүк кайта күрмә!*
*«Үсәбез!» дип, корып беткән өчен*
*Синең алда оят булыр безгә!*

*Ш. Җиһангирова.*

Кайта күрмә, Тукай, кайта күрмә,
Татарлыклар бездә чамалы.
Туган телне санламаган өчен
Оялу да инде калмады.

Битарафлык чире ковидтан да
Ныграк тамыр җәя җаннарда.
Тамчы кадәр генә калып бара
Иман һәм Рух безнең аңнарда.

Сәхнәләрне чын җырчылар түгел,
Такмак җырлаучылар басканга,
Моң тәнчегә бармак белән генә
Санарлыктыр безнең каннарда.

Югалтулар авырлыгын үлчәр
Юктыр, юктыр олы бизмәннәр.
Халкын халык итеп саклап торган
Күпме ауды, ава имәннәр.

Сан артыннан көн-төн куа торгач,
Онытылды сыйфат дигәне.
Он иләргә генә кулланыла
Вак тишекле заман иләге.

Татар гаиләсендә урыс телле
Бала үсүенә күнектек...
Ләббәйкә дип торып, куштанланып,
Кечерәеп калдык,без чүктек.

Шапырынып кына: “Үсәбез!”- дип,
Гөрләп үсеп китеп булмый шул.
Бер йодырык булып төйнәлмәгәч,
Көчле халык булып булмый ул.

Укмашмагач бүре өере кебек,
Куркытасың ничек этләрне?
Газиз телгә хыянәт иткән икән,
Татар дисең ничек безләрне!

Кайта күрмә, Тукай!

Кайтма!

Күрмә!

Татарлыклар бездә чамалы.

Анысы да чыгып бетмәс димә...

Оялу бит бездә калмады.

Оялу бит бездә калмады.

2023 ел, апрель.

**Камил Фазлый**

## БӘХЕТЛЕМЕН

Сабый чакта бөек Тукай
Авырлыклар кичергә.
Тормыш аны үгисетеп,
Ятим итеп үстергән.
Туган теле – ана теле –
Таянычы, юлдашы.
Изге татар теле аның
Бөеклеккә юл башы

Кырлай яланнары кебек
Ифрат гүзәл иртәләр.
Башымнан сыйпап уята
Туган телем, иркәләп.

11 март 2019.

**Хәмит Тәүхетдин**

## ТАТАР ДАНЫ

Тукай. Синең язмышыңны
Балачактан аңладым да,
Сурәтеңнән шомлы караш
Тора гел күз алларымда.
Газиз башың читкә борып,
Сызландыңмы, моңландыңмы?
Хафаланып телең, халкың
Киләчәген уйладыңмы?
“Шигырь, шагыйрь” төшенчәсен
Синең исем аша белдем.
Туган телгә ярату да,
Горурлык та синнән килде.
Укыганда Кушлавычны,
Кырлаеңны күрәм кебек,
Табигате хозурлыгы
Рәхәтлеккә төрә кебек.
Җырлы, нурлы, дәртле Казан
Сокландырган, рухландырган.
Милләтебез аклыгына
Бер-бер артлы шигырь туган.
Шүрәледән курыкмаска,
Алтыннарга кызыкмаска,
Кече яшьтән өйрәттең син
Таз булсаң да боекмаска.
Моңлы сазың, милли көйләр
Нечкә хисле күңелеңә
Илһам биреп җилкендергән
Татар иле киңлегенә.

Безнең якның чибәре дә

Шагыйрь җанын сөендергән.

Уфа, Ырынбур татары

Заманында сине күргән.

Тугансың син татарыңны,

Татар сине данлар өчен.

Синең үлмәс исемеңдә

Мәңге яңгырар шигырь көче.

**Илдус Фазлетдинов**

**ТУКАЙ ҮПКӘСЕ**

Бәгъзе кемдер әйтте:

“Тукай булган

Чахоткалы, черек үпкәле.

Шуңа күрә аның тавышы да

Үз яныннан ерак китмәде”.

Юк, алдама!

Һәрбер шигыреннән

Ишетелә Тукай тавышы.

Бу тавышта – чал кылганнар моңы,

Бу тавышта – халкым сагышы.

Бу тавышта яңрый Кол Шәрифнең

Соңгы тапкыр әйткән азаны:

“И, Ходаем,

берүк чит-ятларга

Калдырмачы газиз Казанны!”

Бу тавышка сыйган татарымның
Данлы-зарлы ерак үткәне.
...Шул үткәннәр канлы
ярчык булып,
Тишеп үткән, ахры, үпкәне.

Җаннар айкый торган
Тукай тавышы
Кая гына барып җитмәгән!
Кыйтгаларны, гасырларны кичкән,
Чыкса да ул ертык үпкәдән.

...Ә без бүген ике күзле килеш
Борыннардан ары күрмибез.
Колаклар бар, ләкин ишетмибез;
Аяклар бар, ләкин йөрмибез.

Җырларына халык зарын салган
Шагыйрьләрне өзелеп көтәбез.
...Тавышыбыз яныбыздан китми –
Таза микән безнең үпкәбез?

**ШАГЫЙРЬ**

Кыл өстеннән Шагыйрь атлап бара,
Әйди алга өмет-хыяллар.
Бер ягында төпсез упкын ята,
Бер ягында – горур кыялар.

Кыяларга бөркет оя корган,
Кыяларда Кояш ялкыны.

...Упкын төбен кара елан саклый,
Өтеп ала кабер салкыны.

Туры карап Шагыйрь алга атлый,
Кыл-йөрәге әрни, кансырый.
Кайгылары аягыннан тарта –
Корбан сорый упкын, җан сорый.

...Шагыйрь гомере – сират күпер кичү,
Күкләр язган аның язмышын.
Ходай Тәгаләнең күз яше ул –
Җырга күчкән моңы-сагышы.

Шигыреннән йөрәк каны саркый,
Шагыйрь күңеле тоташ яра ул.
...Өзелергә торган гомер буйлап
Мәңгелеккә атлап бара ул...

**Фәһим Минһаҗев**

## ШАГЫЙРЬ КИРӘК

*"Тукай кирәк,*
*Тукай кирәк..."*
*М. Кәримов*

Тукай кебек инсаннарны
Үзеңдә үстереү кирәк.
Чүбек чәйнәп кенә тумый
Халыкка булырдай терәк.

Тукай кебек әдипләрне
Гасырлар тудыра сирәк.

Алдашуны тотып селккән
Тукай җанлы шагыйрь кирәк.

Базарларга чыгып чалма,
Яман сөйләп ятьмә тартма.
Тукай кебек кеше сирәк,
Заманадан шагыйрь кирәк.

Күпме сөйләп шапырынма,
Җаныңны бәргәләп ватма...
Тукай кебек шагыйрь сирәк,
Тукай кебек шәхес кирәк.

Пычраклыкны чөеп аткан,
Ваклыкларны өеп яккан
Тукай кебек шагыйрь сирәк,
Заманага шагыйрь кирәк.

Халыктан көч-куәт алган,
Шуларны рухына салган
Тукай кебек шагыйрь сирәк,
Илебезгә шагыйрь кирәк.

Милләте өчен җанын аткан,
Чуар ялганнарны ачкан
Тукай кебек шагыйрь сирәк,
Бүген шундый шагыйрь кирәк.

Шәм урынына җанын яккан,
Үз иленең йөген тарткан

Тукай кебек шагыйрь сирәк,
Бу җиһанга шагыйрь кирәк.

Дошманның көчен ваклаган,
Халкының телен саклаган
Тукай кебек шагырь сирәк,
Халкыбызга шагыйрь кирәк.

Вәхшилекне чалып еккан,
Начарлыкны салып сыккан
Тукай кебек шагыйрь сирәк,
Безгә шундый шагыйрь кирәк.

Һич яраклаша алмаган,
Базарларны селкеп салган
Тукай кебек шагыйрь сирәк,
Безгә бүген шагыйрь кирәк.

Үз иленең даны булган,
Аңардан гәүһәрләр туган
Тукай кебек шагыйрь сирәк,
Халкыбызга шагыйрь кирәк!..

## ИЗГЕ ТУКАЙ

*"Бай киенгән франт – шикларча*
*халык тиресе белән..."*
*Г. Тукай*

Тукай елы игълан иткәч,
Искә төште шулары:

Тукай – халык бөтен булып
Гөрөлдәшкән шаулары.

Тукай халыкны тыңлаган,
Халык аны зурлаган,
Туган улы итеп яклап,
Үз исемен юллаган.

Черегән кара байларны
Тәнкыйтьләгән, ул төткән;
Яндырган да ялкынында,
Кызу кояш күк өткән.

Бернинди үзгәрешләр дә
Каршы киртә кормаган.
Соңгы сулышына кадәр
Халкын яклап җырлаган.

Арабыздан бүген кем бар
Хәл итүче язмышны?!
Еллар буе тулып яткан
Төзәтүче ялгышны.

**Мөнир Вафин**

**ТУКАЙГА ЭНДӘШҮ**

Тукай, Тукай...
Синең яшеңне дә,
Күптән инде, күптән узганга.

Син яшисең, ә мин тере
килеш
Әйләнепләр барам тузанга.

Балачакта ишек төпләрендә
Тормаганмын һичбер өшептә.
Асрамага беркем алмас иде
Әллә күпме акча кушып та.

Без язганнар шундук
искерәләр,
Син язганнар һаман өр-яңа.
Тишек үпкә аша карау җитми
Бу целлюлит баскан дөньяга

Кымыз эзләп
күпме җир гизгәнсең,
Чалбар балакларың
сызганып.
Безгә рәхәт –
хәмер чөмерәбез,
Кымыз өчен акча кызганып.

Ничек мөмкин
сүнмәс нур калдырып,
Бер мизгелдә янып бетәргә?
Әйтче, Тукай,
ничә гомер кирәк
Синең яшькә
килеп җитәргә?..

**Фәнис Гыймазетдинов**

## БАРМЫЙМ ӘЛЕ МИН КЫРЛАЙГА

Бармыйм әле мин Кырлайга,
Безнең авыл да шундый.
Безнең авыл тавыгы да
Бик матур итеп җырлый.

Күптән чишелгән Тукайның
Шигърият мендәре.
Акыл сүзләре шагыйрьнең
Сокландырмый кемнәрне!

Бармыйм әле мин Кырлайга,
Ул – әкият оясы.
Безнең якта да бардыр ул
Шүрәле, Су анасы.

Мин сүрәттә генә күрдем
Шушы бөек кешене.
Горурланам Тукай белән:
Без – бер милләт кешесе!

Бармыйм әле мин Кырлайга,
Тукай сөйләде аны.
Шагыйрьдән дә матурырак
Тасвирлап булмас тагы.

**Мәҗит Кәримов**

## ТОРМЫШКА АШМАС ХЫЯЛ

Балачагым белән аймылыштык,
Үстем инде, менә буй җиттем.
Балачакның йөзен күрәлмәдем:
Ул кайдадыр калды, мин киттем.

Аяк басып тәпи киткән көйгә
Басты мине дөнья нуҗасы,
Дөнья мәшәкате миңа калды –
Җиде яшьтән нигез хуҗасы.

Уен дигәннәре нәрсә икән,
Шуны килә һаман беләсем,
Үткәнемне, тома ятим калган
Балачагым килә күрәсем.

Шагыйрь булгач Тукай, дан казангач,
Агач атка, имеш, атланган.
Димәк, Тукай бер мизгелгә генә
Балачакларына кайталган.

Кайчагында минем карусельгә
Утырасым килә үтереп.
Трай тибәр идем тартынмыйча,
Нәкъ сабыйлар кебек иттереп.

Хәзер инде олыгая барам,
Чәч агара, яшь тә ярыйсы,

Таяк атка менеп атланып,
Агач кылыч билемә тагып,
Бөек Тукай сыман шатлыктан
Бер уйныйсы иде картлыкта!..

**Рәзилә Игебаева**

## ТАТАР ТЕЛЕ, ТУГАН ТЕЛЕ

Тукай бөек куркыта да,
Илһамландыра мине.
Сөйләшик татар телендә
Гөрләтик туган илне.

Әлдә татар булганмын мин,
Татарларда көч-куәт.
Үз телемдә сөйләшкәнгә
Аңа туды мөхәббәт.

Яраттым мин үз телемне
Әткәм-әнкәмнең телен.
Туган авылым Якшай да,
Ачылды минем телем.

Туган телем, татар телем,
Нурлы, кояшым сыман.
Бөтен дөнъяга җылылык,
Яктылык тарата сыман.

Габдулла Тукай язган җырны,
Онытмабыз һичкачан.

“И туган тел, и матур тел” – диеп
Җырлап яшибез хаман.

Татарыма чын Тукайча
Дустым дип дәшермен.
Туган телдә шигырь язып
Җырлар язып яшәрмен.

**Кәбирә Габдрахманова**

**ТУКАЙ БӘЙРӘМЕ**

Ашкынып килдек без монда,
Охшап очкан кошларга;
Халыкның сөекле Тукаен,
Зур шагыйрьне котларга.

Бүген бит Тукай бәйрәме,
Бездә бик зур тантана.
Шуңа күрә кояш көлә,
Гөлләр шуңа шатлана.

Габдулла Тукай өйрәтте
Сөяргә туган телне;
Күз алмасы кебек күреп,
Сакларга газиз илне.

Бөек син, Габдулла Тукай,
Синең эздән барабыз.
Туган телдән, туган җирдән
Яшәргә көч алабыз.

**УКУЧЫЛАР ИҖАТЫ**

**Алия Ногыманова**

**ТУКАЙ - ЙӨРӘКТӘ!**

Кечкенәдән ятим калып,
Авырлык күргән Тукай.
Язмыш шулай җәберләүгә
Гаепleme бу малай?

Ләкин Апуш бирешмәгән,

Гел алга таба барган.

Ач-ялангач дип тормаган,

Тырышып белем алган.

Еллар үткән, Тукай безнең

Халкыбызны таныткан.

Шуңа күрә аны барсы

Мәңгелеккә яраткан.

Тукай ул – татар шагыйре,

Безнең халык кешесе!

Аны йөрәкләрдә мәңге

Саклап килә яшисе!

**Камила Арсланова**

**ТУКАЙ БАБАМ**

Габдулла Тукай бабамны

Беләм мин кече яшьтән,

Әнием белән әкиятләрен

Өйрәнгән идем баштан.

Зирәк Кәҗә белән Сарык

Маҗараларын тыңлап,

Шүрәле һәм Су анасын

Гаҗәпләндем күзаллап!..

Үсә төшкәч, шигырьләрен

Ятлый башладым теләп.

Рәсемнәр дә төшерәм мин

Иҗатына багышлап.

Тукай бабам васыятләрен
Калдырган безгә язып:
- Акыллы булып үсегез, -
Дигән, - тырышып укып.

**Харисова Алина**

**ТУКАЙ АБЫЙ**

Тукай абый кем дисезме?
Тукай абый – шәп абый!
Шәп абыйгына түгел ул,
Тукай абый – вәт абый!

Тукай абый шигырьләре,
Уйната да уйлата.
Уйлатып кына калмый ул,
Яшәү серен аңлата!

**ЭЧТӘЛЕК**

Укучыга сүз ------------------------------------------------------------ 1
Минем һәр минутым бөтен дөнья бәһасенә тора...-------------- 2-3
Г. Тукай.
Туган тел--------------------------------------------------------------- 4

Салихова Зәйфә

Тукай кайтты------------------------------------------------------------ 5-6
Апрель ае, Тукай ае-----------------------------------------------------6-7
Тукайга туган көнендә ---------------------------------------------------7
Ә Тукай яшәр ------------------------------------------------------------7-8
Тукай дисәм --------------------------------------------------------------8
Рәхмәт, Тукай ------------------------------------------------------------8-9
Тукай дигән бер дөнья бар ---------------------------------------------9-10
Апрель -------------------------------------------------------------------10-13
Рәхмәт, языми ------------------------------------------------------------13-14
Бу көн ---------------------------------------------------------------------14-16
Тукай китми ---------------------------------------------------------------16
Кем ул Тукай -------------------------------------------------------------16-17
Тукай белән сөйләшү ----------------------------------------------------17-19
Мин Тукайга киләм -----------------------------------------------------19-21
Тукай безнең белән------------------------------------------------------21-22
Тукай. Заман. Без. циклыннан Кайта күрмә ----------------------22-24

Камил Фазлый
Бәхетлемен --------------------------------------------------------------24

Хәмит Тәүхетдин
Татар даны -----------------------------------------------------------------25-26
Илдус Фазлетдинов
Тукай үпкәсе -------------------------------------------------------------26-27
Шагыйрь ---------------------------------------------------------------------27-28

Фәһим Минһаҗев
Шагыйрь кирәк ----------------------------------------------------------28-30
Изге Тукай ----------------------------------------------------------------30-31

Мөнир Вафин
Тукайга эндәшү ----------------------------------------------------------31-32

Фәнис Гыймазетдинов
Бармыйм әле мин кырлайга ----------------------------------------------33

Мәҗит Кәримов
Тормышка ашмас хыял ---------------------------------------------------34-35

Рәзилә Игебаева
Татар теле, туган теле -------------------------------------------------35-36

Кәбирә Габдрахманова
Тукай бәйрәме -----------------------------------------------------------36

Укучылал иҗаты---------------------------------------------------------37-38

Ногыманова Алия
Тукай йөрәктә-------------------------------------------------------------37

Арсланова Камила
Тукай бабам-------------------------------------------------------------37-38

Харисова Алина
Тукай абый----------------------------------------------------------------38

Эчтәлек-------------------------------------------------------------------39-40

Тукайга шигъри чәчкәләр : Шигырьләр [Бәләбәй шагыйрьләренең Габдулла Тукайга арналган шигырьләре] / Төзүче Сәлимова Р.М. – Бәләбәй : Үзәк китапханәсенең милли әдәбият һәм туган якны өйрәнү бүлеге. – 2023. – 40 бит.

г. Белебей

Центральная библиотека

ул. М.Г. Амирова, 13

mukcbs09@mail.ru

http://belebeycbs.ru